СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**04 октябрь 2016 ел** **№ 25**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының 30.09.2016 ел, №12 «референдум үткәрү инициативасы турында " гы Карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 30.09.2016 ел, №23 «референдум үткәрү инициативасы турында» гы карары нигезендә, Иске Кырлай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 20 ноябренә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2017 елда Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә сез ризаме, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, Чернобыль АЭСындагы аварияне бетерүдә катнашучылардан, 75 яшьтән өлкәнрәкләрдән тыш, алар өчен түләү күләме 100 сум тәшкил итә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

- юлларга вак таш салу.: - Иске Кырлай авылы (Һади Такташ ур., 1 нче йорттан 7 нче йортка кадәр-150 м); - Иске Иябаш авылы (Муса Җәлил урамы, 46нчы йорттан 47нче йортка кадәр-18 м); - Өтнә авылы (Салих Сәйдәшев ур., 15-нче йорттан 16-48м

йортка кадәр); - Югары Әзәк авылы (Мәктәп урамы, 8 йорттан башлап 10йортка кадәр - 60м);

- Түбән Мәтәскә авылы (Тукай ур., 14,14 а-20м), (Түбән йорттан 1,2-40м), (Киров ур., 7 йорттан 15-60м йортка кадәр), (Мәктәп ур., 4,115-60м), (Тынычлык ур., 6 йорттан 11-50м йортка кадәр), (Татарстанга чыкканда-20м);

- Югары Мәтәскә авылы (Дуслык урамы 1 нче йорттан 4-20м йортка кадәр), (Тукай урамы, 2,4,6-40м, 9,11,15-60м номерлы йорттан), (Яшьләр урамы, 1 нче йорттан -20 м); - Мөндеш авылы (Чишмә ур., 33 нче йорттан 39 йортка кадәр-80м, 5 нче йорттан 9 номерлы йортка кадәр-80м), (Татарстан ур., 25 нче йорттан 28номерлы йортка кадәр-60м); -Казиле авылы ( Җиңү ур., 11 йорттан 14 йортка кадәр-70м).

- Иске Иябаш авылында коймалар урнаштыру (120м) һәм зиратларны тоту.

Экономияләнгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

Әйе юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай ур., 2й; ТР, Арча районы, Иске Кырлай авылы, Үзәк ур., 12А й.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Сиражетдинов

СОВЕТ СТАРОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ